**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**10 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен**
**татар теленнән үткәрелә торган республика олимпиадасының**
**муниципаль этабы өчен биремнәр**
**(2014/2015 нче уку елы)**

I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез

1. Татар теленең формалашу этаплары дөрес билгеләнгән рәтне күрсәтегез.
   а) ностратик → урал-алтай → алтай → төрки → угыз → татар;
   ә) урал-алтай → ностратик → төрки-монгол → төрки → чуваш → татар;
   б) ностратик → урал-алтай→ алтай → төрки-монгол →төрки → кыпчак → татар;
   в) урал-алтай → ностратик → төрки-монгол → төрки → угыз → кыпчак → татар.

2. *Тәнкыйть, сәнгать, башлангыч, манган* сүзләрен нинди фонетик закончалык берләштерә?
   а) ассимиляция;
   ә) диссимиляция;
   б) аккомодация;
   в) сингармонизм.

3. Тартык авазларның төре ягыннан аерылып торган сүз кайсы җөмләдә?
   а) Белеме бар меңне егар;
   ә) Булганнан бар да була;
   б) Зиннур абый балаларга белем бирә;
   в) Гөлнурның әтисе – Казан-Аренада менеджер.

4. Кайсы мәкальдә рәт гармониясенә буйсынмаган сүз бар?
   а) Эш беткәч, уйнарга ярый;
   ә) Язның бер көне ел туйдыра;
   б) Кырык өйдән кырык бер сохари;
   в) Күршеләргә туй килсә, син дә капкаң ачып куй.

5. Болар нинди сүзләр?
*Ярлык, чабата, хан, комсомол, казый*.
   а) архаизмнар;
   ә) тарихи сүзләр;
   б) диалектизмнар;
   в) неологизмнар.

6. Фразеологизмның мәгънәсе ничек?
*Ут йоту* - ...
   а) уйлау;
   ә) тырышу;
   б) борчылу;
   в) ашау.

7. Этимология ул – ...
   а) ялгызлык исемнәрне өйрәнә;

ә) тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә;
б) сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә;
в) күбәләкләрне өйрәнә.

8. *Карга кунган ак карга* җөмләсендә билгеләнгән сүзләр
а) омофон;
ә) омограф;
б) саф лексик омоним;
в) омоформа.

9. Тамырдаш сүзләрдән генә торган төркемне табыгыз.
а) көндез, көнкүреш, көндәлек, көнозын;
ә) очлау, очлы, очрау, очкыч;
б) көл, көлсу, көләч, көлдергеч;
в) малчы, мал, малкай, малайлык.

10. *Гөрләвекләренә* сүзе нинди мәгънәле кисәкләрдән тора?
а) тамыр, ясагыч кушымча, модальлек кушымчасы, модальлек кушымчасы, бәйләгеч кушымча, бәйләгеч кушымча;
ә) тамыр, ясагыч кушымча, ясагыч кушымча, модальлек кушымчасы, бәйләгеч кушымча, бәйләгеч кушымча;
б) тамыр, ясагыч кушымча, модальлек кушымчасы, бәйләгеч кушымча, бәйләгеч кушымча, бәйләгеч кушымча;
в) тамыр, ясагыч кушымча, ясагыч кушымча, модальлек кушымчасы, модальлек кушымчасы, бәйләгеч кушымча.

11. Сыйфат ясагыч кушымчалар рәтен билгеләгез.
а) -ла/-лә, -чы/-че, -дай/-дәй;
ә) -лы/-ле, -сыз/-сез, -дагы/-дәге;
б) -дай/-дәй, -ча/-чә, -ган/гән;
в) -ып/-еп, -са/-сә, -учы/-үче.

12. Исемнәрдәге күплек кушымчасы кайсы төргә карый?
а) ясагыч;
ә) модальлек;
б) бәйләгеч;
в) төрләндергеч.

13. Җөмләдә билгеләнгән сүз кайсы сүз төркеменә керә?
*Бу чиге юк озын мәңгелектә*
*Бер генә кат яшибез* ***ласа*** (Х.Туфан)
а) ымлык;
ә) модаль сүз;
б) кисәкчә;
в) теркәгеч.

14. Җөмләдәге билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализ кайсы рәттә?
*Идел-йортка килә яңгыр:*
*Тәрәзәгә* ***шыбыр-шыбыр*** *нидер сөйли.*
(Р.Әхмәтҗанов)
а) рәвеш, охшату-чагыштыру рәвеше, җөмләдә рәвеш хәле, парлы сүз;
ә) аваз иярteme, тавыш тасвиры, җөмләдә рәвеш хәле, ясалма (парлы сүз);

б) аваз иярteme, образ тасвиры, җөмләдә рәвеш хәле, парлы сүз;
в) рәвеш, саф рәвеш, җөмләдә рәвеш хәле, парлы сүз.

15. Кайсы җөмләдә исем фигыль кулланылган?

*а) Күп эшләде иренмичә; бара-бара*
*Чыгарды ул матур-матур балалар да.* (Г.Тукай)

*ә) Әйт әле, ничек табасың*
*Шигырьнең ритмын-көен?* (И.Юзеев)

*б) Шигъремдәге чынлык, ут һәм сөю* -
*Яшәвемнең бөтен мәгънәсе* (М.Җәлил)

*в) Телем – шул ук туган илем,*
*Җирдә телсез ил булмый* (Р.Әхмәтҗанов)

16. Билгеләү алмашлыклары гына булган төркемне күрсәтегез.

а) һәркем, кемдер, шул, нәрсә;
ә) барлык, һәммә, үз, бөтен;
б) теге, ул, һичкем, кайдадыр;
в) үземнеке, болай, андый, барча.

17. Иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төре нинди?

*Диләфрүзнең гадәте шундый: палатага килеп кергәч, ул бермәл ишек төбеннән карап тора* (Г.Әпсәләмов)

а) иярчен ия;
ә) иярчен хәбәр;
б) иярчен аергыч;
в) иярчен аныклагыч.

18. Өтер урыннары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Малай (1) бер сүз дә дәшмичә (2) сүземне тыңлап-тыңлап торды да (3) миннән рөхсәт сорап (4) иптәшләре янына йөгереп китеп барды* (А.Ш.)

а) 2, 3, 4;
ә) 1, 2, 4;
б) 1, 2, 3, 4;
в) 1, 3, 4.

19. Җөмләнең төзелеш ягыннан төрен билгеләгез.

*Күк йөзе ерак, сыек-зәңгәр, ә бик биектән төнге яшен тишкәләгән күперенке ак болытлар акрын гына агалар* (Ә.Еники)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
ә) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
б) катнаш кушма җөмлә;
в) иярченле кушма җөмлә.

20. Аерып бирелгән сүз нинди җөмлә кисәге?

*Печән өсте **җиткәнне** без, малайлар, бик зур дәрт белән көтеп алабыз* (Г.Бәширов)

а) аергыч;
ә) тәмамлык;
б) аныклагыч;
в) хәбәр.

## II. Теоретик бирем.

Аныклагыч. Аның аерымлануы. Тыныш билгеләре.

## III. Гамәли бирем 10

*Нәкъ шул минутта бер могҗиза булды: басу өстен каплаган ак болытлар эченнән гөрелдәү ишетелде һәм салкын кар басуына эре-эре яңгыр тамчылары төшә башлады.* (М.Мәһдиев).

1. Тыныш билгеләрен куярга.
2. Җөмлә чикләрен билгеләп, бәйләүче чараларны күрсәтергә.
3. Җөмлә кисәкләренең асларына сызарга.
4. Җөмләнең схемасын сызарга, төрен билгеләргә.
5. *Болыт* сүзенә фонетик анализ ясарга.
6. *Басуына, ишетелде, шул* сүзләренә морфологик анализ ясарга.
7. *Тамчылары* сүзен төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерергә.

## IV. Иҗади бирем

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам.

Г.Тукай

Бу шигъри юллар  Сездә нинди хисләр уятты? Андагы фикерләр бүген дә актуальме? Хис-тойгыларыгызны 10-12 җөмләдән артмаган бәйләнешле текст итеп языгыз.